**Татарстан Республикасы**
**Әлки муниципаль районының муниципальный район**
**Каргалы авыл жирлеге берәмлеге поселение**

**Республика Татарстан**
**Алькеевский**
**Каргопольское сельское**

**Адрес:422875**
**Карга авылы**
**Үзәк ур. 30**
**тел: (243) 77-8-80**
**эл.адр.Ramil.Mingazov@tayar.ru**

**Адрес :422875**
**с. Каргополь**
**ул. Центральная 30**
**тел: (243) 77-8-80**
**эл.адр.Ramil.Mingazov@tayar.ru**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Каргалы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАРЫ

2018 елның 05 феврале № 6

2018 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Каргалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын раслау турында

2002 елның 25 июлендәге «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 114-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 06 мартындагы «Террорчылыкка каршы тору турында» 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 1666 номерлы Әмере, "Каргалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру кысаларында эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгеләү-терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу, шулай ук Каргалы авыл җирлеге территориясендә терроризм һәм экстремизм күренешләрен минимальләштерүдә һәм (яки) алардан килгән зыяннарны бетерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Каргалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планын кушымта нигезендә расларга.
2. Карарны мәгълүмати стендларда һәм «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Каргалы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.В Миңгазов

Расланды
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Каргалы авыл җирлеге башкарма
комитетының 2018 елның 05 февраль 6 номерлы
карары

**2018 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Каргалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар планы**

| т/б № | Чаралар исеме | Җаваплы башкаручы | Үтәү сроклары | Башкару турында тамга |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фондының террорчылыкка каршы якланганлыгын камилләштерү эшен оештырырга | Авыл җирлеге башлыгы | 2018 ел. | |
| 2 | Куркынычсызлыкны көчәйтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру: - торак йортлар һәм кешеләр күпләп була торган урыннар, шул исәптән чормалар; - су җыю скважиналары һәм тормышны тәэмин итүнең башка объектлары;- укыту һәм мәктәпкәчә учреждениеләр, сәламәтлек саклау учреждениеләре, даими яшәү һәм кешеләр күп йөри торган урыннар; | АҖ Башкарма комитеты, учреждение җитәкчеләре (килешү буенча) | Даими | |
| 3 | Террорчылыкка каршы якланганлыкны һәм янгынга каршы куркынычсызлыкны тикшерү максатларында учреждениеләр һәм аларга якын территорияләргә комплекслы тикшерүләр уздырырга | АҖ Башкарма комитеты, янгын саклау хезмәте (килешү буенча), участок полиция вәкиле (килешү буенча) | 2018 елның мае | |
| 4 | Авыл җирлеге территориясендә законсыз булган затларны билгеләү предметына буш торучы һәм арендалана торган биналарны даими рәвештә | Җирлек башлыгы, полиция участок уполномоченные (килешү буенча) | Даими | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тикшерүләр оештырырга | | | |
| 5 | Террорчылыкка каршы көрәш мәсьәләләре буенча укыту, мәктәпкәчә учреждениеләр җитәкчеләре белән киңәшмәләр үткәрү | Авыл җирлеге башкарма комитеты | Август 2018 ел. | |
| 6 | Терроризмга һәм экстремизмга каршы көрәш чаралары турында АҖ халкына даими мәгълүмат бирүне оештырырга | Авыл җирлеге башкарма комитеты, комиссия әгъзалары | 2018 ел, даими | |
| 7 | Террорчылыкның һәм экстремизмның асылын, аның чыганакларын һәм нәтиҗәләрен аңлату максатында мәгариф, мәдәният учреждениеләрендә пропаганда эше уздыруны оештырырга | Учреждение җитәкчеләре (килешү буенча) | 2018 ел. | |
| 8 | Ташландык йортлар исемлеген төгәлләштерү. АҖ территориясендә урнашкан. Әлеге объектларда шикле затларның, предметларның һәм әйберләрнең булу (яшәү) фактлары турында хокук саклау органнарына вакытында хәбәр итәргә. | Авыл җирлеге җитәкчесе. | даими рәвештә | |
| 9 | Торак биналарын наемга тапшыручы затларны һәм гражданнарның торак урыннарында теркәлмичә яшәүнең фактларын ачыкларга. Эчке эшләр бүлегенә үз вакытында хәбәр итәргә | Полиция участок уполномоченные (килешү буенча), АҖ җитәкчесе | даими | |
| 10 | Чит ил эшче көчләрен законсыз файдалану фактларын туктату; Федераль миграция хезмәте идарәсенә Урта Азия һәм Төньяк Кавказ төбәкләреннән килгән эшчеләр турында үз вакытында хәбәр итү | Авыл җирлеге башкарма комитеты | даими | |
| 11 | Террорчылык янавын һәм | Авыл җирлеге башлыгы | даими | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | экстремистик күренешләрне кисәтү, миграция, хокук бозулар өлкәсендә закон бозуларны, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган хокук бозуларын кисәтү буенча профилактик эшне гамәлгә ашыру | | | |
| 12 | Депутатларны хокук бозуларны кисәтү чараларын үткәрүгә җәлеп итү | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2018 ел | |
| 13 | Мәктәпләрдә гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, массакүләм чаралар уздырганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча профилактик эш оештыру. | АЖ җитәкчесе, полиция участок уполномоченные (килешү буенча), учреждение җитәкчеләре (килешү буенча) | квартал саен | |
| 14 | Учреждениеләрнең матди-техник базасын ныгыту, шул исәптән яктырту һәм коймалар, янгынга каршы инвентарь булдыру чараларын күрергә. | Учреждение житәкчеләре (килешү буенча) | 2018 ел | |
| 15 | Авыл җирлеге территориясендәге МБГББУ, МБМББУләрендә терактларын булдырмау максатында укулар һәм күнегүләр үткәрү | «Карга башлангыч мәктәбе» һәм «Карга башлангыч мәктәбе» укытучылары. | Елына бер тапкыр | |
| 16 | Яшәү урыны буенча йөргәндә, җыелышларда халык белән профилактик эш алып бару | Авыл җирлеге башкарма комитеты | апрель-май | |
| 17 | Авыл китапханәсендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча күрсәтмә материаллар әзерләргә | Авыл китапханәсе мөдире (килешү буенча). | 2018 елның июненә кадәр | |